# Китапханә сезне көтә

Мин инде дистә еллап Уфа Үзәк шәһәр китапханәсендә туган якны өйрәнү бүлеге эшләп килә. Бүгенге көндә без – шактый ныгыган, тәҗрибә туплаган, мәктәп укучыларына, студентларга, гомумән, үз укучыларыбызга бик кирәкле бүлекләрнең берсе. Үз фондыбызда булган китап, журналларны тәкъдим итеп кенә калмыйбыз, әдәби-мәдәни очрашулар, бәйрәмнәр, кичәләр үткәрәбез, төрле чараларда, конкурсларда теләп катнашабыз. Туган якны өйрәнү бүлеге шулай ук шәһәр китапханәләренә даими рәвештә методик ярдәм күрсәтә.

Күренекле язучыларыбызга багышланган әдәби очрашуларның иң истә калганы – Р. Гариповның 75 еллыгына багышланган "Җырларыма кайтам" әдәби музыкаль кичәсе булгандыр. Рәми аганың тормыш иптәше Надежда Васильевна белән очрашу хәтердә уелып калды. Габдулла Тукайның иҗатына багышлап үткәрелгән "Тукай җыры" тип исемләнгән музыкаль-поэтик кичә шулай ук бик ямьле үтте. Милли матбугат хезмәткәрләре белән иҗади очрашулар әледән-әле кабатланып тора. Соңгы чорда "Аманат", "Агиҙел", "Тамаша", "Тулпар", "Шоңкар", "Башкортостан", "Кызыл таң" хезмәткәрләре белән бу басмаларның юбилей тантаналарын билгеләп үттек.

Хәзерге көндә Башкортстанда яшәгән халыкларның туган телләрен, мәдәниятен, традицияләрен, гореф-гадәтләрен, рухи дөньясын үстерү проблемасы беренче планда тора. Бу җәһәттән башкортларның "Ак тирмә", татарларның "Сәхипҗамал" иҗтимагый оешмалары, украиннарның "Кобзарь", чувашларның "Нарспи", урысларның "Таусень" фольклор коллективлары белән тыгыз бәйләнештә торабыз. Уфа шәһәренең 65нче, 84нче санлы татар гимназияләре укытучылары һәм укучылары – безнең әдәби-мәдәни чараларда һәрчак кадерле кунак.

Башкортстан Язучылар союзы белән дә уртак эш алып барыла. Язучылар, шагыйрьләр без оештырган чараларга, очрашуларга бик ихлас, җаваплы карыйлар, зур әзерлек һәм үз көчтәнәчләре белән киләләр. Бүлектә иң күркәм күргәзмәләренең берсе – Башкортстан язучылары автографлары куелган китаплар киштәсе.

Милли бүлек хезмәткәрләре укучыларны һәрчак көтеп кала.

***Гөлнур ГЫЙМАЛЕТДИНОВА,***